Сабантуй

ХӘЕРЛЕ ЮЛ!

Юлда имин йөрү кагыйдәләре

СЧАСТЛИВОГО ПУТИ!

Правила безопасного поведения на дорогах

ББК 74.200.58 (2Рос=Тат)
УДК 821.512.145
У18
«Тормыш иминлеге фәнни үзәге» ДБУ тәкъдим итә.
Рекомендовано ГБУ «Научный центр безопасности жизнедеятельности».

Рецензентлары:
Попов В.Н., «Тормыш иминлеге фәнни үзәге» ДБУ «Юл хәрәкәте иминлеге» бүлеге җитәкчесе;
Сафиуллина Г.М., Казан шәһәре Совет районының «65 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире.

Рецензенты:
Попов В.Н., начальник отдела «Безопасность дорожного движения» ГБУ «Научный центр безопасности жизнедеятельности»;
Сафиуллина Г.М., заведующая МАДОУ «Детский сад №65 комбинированного вида» Советского района г.Казани.

Рәссамы – ***Влада Семёнова***

Уваева Р.К.
У18 Хәерле юл! = Счастливого пути! – Казан : «Сабантуй» журналы редакциясе, 2022. – 48 б. : рәс. б-н.

Бу китап мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм башлангыч сыйныф укучыларын юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләре белән таныштыра. «Юл билгеләре» бүлегендә балалар белергә тиешле юл билгеләре минимумы тәкъдим ителә. «Мин – җәяүле» бүлеге – җәяүлеләр өчен кагыйдәләр, «Мин – пассажир» – транспортта һәм тукталышларда үз-үзеңне тоту нормалары, «Мин – йөртүче» бүлеге велосипедта дөрес йөрү кагыйдәләре турында сөйли. Китапта төрле очракларда беренче ярдәм күрсәтү ысуллары да күрсәтелә. Һәр кагыйдә рәсем белән бизәлгән. Китапның ахырында белемнәрне ныгыту өчен 10 бирем, ә кушымтада 3 өстәл уены бар.

Данная книга знакомит детей дошкольного возраста и учащихся начальных классов с правилами безопасности дорожного движения. В разделе «Дорожные знаки» предлагается минимум дорожных знаков, которые должны знать дети. Раздел «Я – пешеход» рассказывает о правилах для пешеходов, раздел «Я – пассажир» – о нормах поведения на транспорте и на остановках, раздел «Я – водитель» – о правилах безопасной езды на велосипеде. В книге излагаются способы оказания первой помощи в различных случаях. Каждое правило дополнено рисунком. В конце книги есть 10 заданий для закрепления знаний, а в приложении – 3 настольные игры.

© «Сабантуй» журналы, 2022
© Уваева Р.К., 2022

Эчтәлек — Содержание

УРАМ ҺӘМ ЮЛ	2	УЛИЦА И ДОРОГА
ЮЛ БИЛГЕЛӘРЕ	4	ДОРОЖНЫЕ ЗНАКИ
МИН – ҖӘЯҮЛЕ	19	Я – ПЕШЕХОД
МИН – ПАССАЖИР	24	Я – ПАССАЖИР
МИН – ЙӨРТҮЧЕ	29	Я – ВОДИТЕЛЬ
БЕРЕНЧЕ ЯРДӘМ	34	ПЕРВАЯ ПОМОЩЬ
УЕН-БИРЕМНӘР	42	ИГРЫ-ЗАДАЧИ
ҖАВАПЛАР	48	ОТВЕТЫ

1 **УРАМ** – торак пунктның юл, биналар, юл билгеләре, җәяүлеләр кичүен үз эченә алган бер өлеше.

УЛИЦА – часть населённого пункта с дорогой, дорожными знаками, пешеходными переходами, зданиями.



2 **ЮЛ** – транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәте өчен эшләнгән яки җайланган ясалма корылма өслеге яки җир полосасы.

ДОРОГА – полоса земли или поверхность искусственного сооружения, обустроенная или приспособленная для движения транспортных средств и пешеходов.

3 **СВЕТОФОР** – юлларда транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен көйләүче төрле төстәге пыялалы, яктылык сигналлары таратучы җайланма.

СВЕТОФОР – светосигнальное устройство с разноцветными стёклами для регулирования движения на дорогах транспортных средств или пешеходов.

4 **ЮЛ ЧАТЫ** – бер дәрәҗәдәге юлларның кисешү, кушылу яки тармаклану урыны.

ПЕРЕКРЁСТОК – это место пересечения, примыкания или разветвления дорог на одном уровне.

5 **ЙӨРҮ ӨЛЕШЕ** – юлның рельссыз транспорт чаралары өчен булган элементы.

ПРОЕЗЖАЯ ЧАСТЬ – элемент дороги, предназначенный для движения безрельсовых транспортных средств.

7

ТРОТУАР – җәяүлеләр юлы. Ул йөрү өлеше яки велосипед юлы белән янәшә урнашкан яки алардан газон белән бүленгән була.

ТРОТУАР – элемент дороги, предназначенный для движения пешеходов. Он примыкает к проезжей части или велосипедной дорожке либо отделяется от них газоном.

8

АВТОМОБИЛЬЛӘР АГЫМЫН АЕРУЧЫ ПОЛОСА – конструктив рәвештә һәм (яки) «узу өлеше кырые» тамгасы белән бүленгән, чиктәш йөрү өлешләрен, шулай ук йөрү өлеше һәм трамвай юлларын аера торган юл элементы. Анда транспорт чараларына туктарга һәм хәрәкәт итәргә ярамый.

РАЗДЕЛИТЕЛЬНАЯ ПОЛОСА – элемент дороги, выделенный конструктивно и (или) с помощью разметки «край проезжей части», разделяющий смежные проезжие части, а также проезжую часть и трамвайные пути и не предназначенный для движения и остановки транспортных средств.

6

ҖӘЯҮЛЕЛӘР КИЧҮЕ – йөрү өлеше, трамвай юлларының 5.19.1 и 5.19.2 билгеләре белән билгеләнгән өлеше. Җир өслегендәге, җир өсте һәм җир асты кичүләре була.

ПЕШЕХОДНЫЙ ПЕРЕХОД – участок проезжей части, трамвайных путей, обозначенный знаками 5.19.1 и 5.19.2. Пешеходные переходы бывают наземные, надземные и подземные.

Юл билгеләре – бөтен дөньядагы автомобиль йөртүчеләр һәм җәяүлеләр өчен үзенчәлекле тел ул. Әлеге китапта түбәндәге билгеләрнең иң мөһимнәре тәкъдим ителә:

– кисәтү (1.1 – 1.25),
– өстенлек бирү (2.1 – 2.5),
– тыю (3.1 – 3.28),
– боеру (4.1.1 – 4.5),
– махсус боерык бирә торган (5.16 – 5.33),
– мәгълүмат (6.6 – 6.8.1),
– сервис билгеләре (7.1 – 7.11).

Һәркайсының кыскача аңлатмасы да бар. Юл билгеләрен кисеп алып, карточка рәвешендә файдаланырга да мөмкин. Аңлатмасын табу өчен, билге номерына карагыз.

Дорожные знаки – это особый язык для водителей и пешеходов во всем мире. В этой книге представлены наиболее важные из следующих групп дорожных знаков:

– предупреждающие знаки (1.1 – 1.25),
– знаки приоритета (2.1 – 2.5),
– запрещающие знаки (3.1 – 3.28),
– предписывающие знаки (4.1.1 – 4.5),
– знаки особых предписаний (5.16 – 5.33),
– информационные знаки (6.6 – 6.8.1)
– знаки сервиса (7.1 – 7.11).

У каждого знака есть краткое объяснение. Дорожные знаки можно вырезать и использовать в виде карточек. Чтобы найти объяснение, посмотрите на номер знака.



1.1

ШЛАГБАУМЛЫ ТИМЕР ЮЛ КИЧҮЕ
ЖЕЛЕЗНОДОРОЖНЫЙ ПЕРЕЕЗД СО ШЛАГБАУМОМ

Бу билге шлагбаум белән җиһазланган тимер юл кичүенә якынлашу турында кисәтә. Шлагбаум тимер юлның ике ягына да урнаштырыла. Автомобиль йөртүче шлагбаум алдында туктарга әзер булырга тиеш.

Этот знак предупреждает о приближении к переезду, оборудованному шлагбаумами. Шлагбаумы устанавливаются с обеих сторон железнодорожных путей. Водитель должен быть готов к остановке перед шлагбаумом.

1.1